КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 11 сентябрь г.Казань № 856

Россия Федерациясе төбәкләрендә (Татарстан Республикасыннан тыш) этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен һәм Россия Федерациясе төбәкләрендә (Татарстан Республикасыннан тыш) этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү советы составын раслау хакында

Россия Федерациясендә татар телен саклап калу, татар милли мәдәниятен үстерү һәм популярлаштыру, бу өлкәдә гражданнар инициативаларына ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе төбәкләрендә (Татарстан Республикасыннан тыш) этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын гамәлгә куярга.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Россия Федерациясе төбәкләрендә (Татарстан Республикасыннан тыш) этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен;

Россия Федерациясе төбәкләрендә (Татарстан Республикасыннан тыш) этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү советы составын.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 11 сентябрь, 856 нчы
карары белән расланды

Россия Федерациясе төбәкләрендә (Татарстан Республикасыннан тыш) этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү советы составы

| | |
|---|---|
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, Совет рәисе |
| Гыйльметдинов Илдар Ирек улы | «Татарларның федераль милли-мәдәни автономиясе» иҗтимагый оешмасы советы рәисе, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Шакиров Данис Фәнис улы | Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Мифтахова Алсу Равил кызы | «Татарстан Республикасы мәдәнияте өлкәсендә инновацияләрне кертү һәм традицияләрне саклап калу буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, Совет секретаре |

Совет әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әдһәмова Юлия Илдар кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары |
| Вәлиев Рафаэль Миргасыйм улы | югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты директорының фәнни эшчәнлек буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Габдрахманова Гөлнара Фаат кызы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесенең этнологик тикшеренүләр бүлеге мөдире |

| | |
|---|---|
| Заһидуллина Дания Фатыйх кызы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе вице-президенты |
| Зәйдуллин Ркаил Рафаил улы | «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» иҗтимагый оешмасы (Иҗади берлек) рәисе (килешү буенча) |
| Миңнуллин Ким Мөгаллим улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры |
| Миргалимов Илдар Флүс улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары |
| Мостафин Данил Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментына караган Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Низамова Ләйсән Гаптелхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |
| Сафиуллина Рәисә Гариф кызы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы (килешү буенча). |